| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2024 ел Кошман ав. № 73

Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2015 елның 12 октябрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 статьяның 4 абзацында «салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан» сүзләрен «салым түләүчеләр тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 0,3% торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);»;

- 2 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 0,12% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, бакчачылык яисә яшелчәчелек, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата»;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга һәм Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р. Сафина